


# «Идел-йорт» җиңүчесе – Актаныш районы

**Районның Киров авылы халык театры Шамил Закиров исемендәге XX «Иделйорт» театр коллективлары төбәкара бәйгесенең Гран-приена лаек булды. Җиңүчеләрне бу атнада Казанда Г.Камал театрында бүләкләделәр. Киров авылы театрына 1 миллион сум күләмендә акчалата бүләк тапшырылды.**

Алинә **Айдарова**



С.Камалетдинов фотосы

Бәйгедә тагын бер Гран-при иясе – Башкортстан Республикасы Стәрлебаш авылының «Эстәрле» халык театры 500 мең сумга лаек булды.

**«Иң яхшы хатын-кыз роле»** номинациясендә Башкортстанның Балтач районы мәдәният сараеның «Балкыш» татар халык театры актеры Розалия Хәмәтнурова, Менделеевск районы Бәзәкә авылы мәдәният йортының «Елмай» халык театры артисткасы Фәимә Галимова бүләкләнде.

Ульяновск шәһәре «Киндяковка» мәдәният йортының «Нур» халык театры актеры Мәүлетдин Таҗетдинов, Удмуртиянең Ижевск шәһәре «Чулпан» үзешчән театры актеры Радик Сәфәров, Актаныш районы Иске Сәфәр авылы халык театры актеры Әлфис Әхмәтшәриповка **«Иң яхшы ир-ат роле»** номинациясендә тиңнәр булмады.

**«Иң яхшы эпизодик роль»** номинациясендә җиңгән артистларга, **«Үзешчән театр сәнгатенә зур өлеш керткән өчен» режиссерларга, сәнгать җитәкчеләренә һәм** бәйгенең лауреатлары, дипломантлары булган халык театрлары коллективларына да бүләкләр тапшырылды.

2021 елда Актаныш районында Татар дәүләт театрын ачарга ниятлиләр. «2021 ел Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Актаныш халкы һәм татар дөньясы өчен 2021 ел Татар дәүләт театры оешу белән истә калсын. Киләсе елда әлеге театрның гастрольләрен оештыруны да үз өстебезгә алабыз», – дип хәбәр итте конгрессның Башкарма комитеты җитәкчесе **Данис Шакиров**.

– Бу фестивальне оештыручыларга – Мәдәният министрлыгына, конгресска, жюри әгъзаларына рәхмәт белдерәм. Актаныш районында яшәүчеләрнең 99 процентын татарлар тәшкил итә. Тарихи бурычыбыз – татар дөньясына иҗади шәхесләр үстерү. Татар дәүләт театрын булдыру – зур максатыбыз. Киләсе елда дәүләт театры дәрәҗәсенә ирешү өмете белән эшлибез, – диде Актаныш районы башлыгы **Энгель Фәттахов**.

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# КОЛЛЕКТОРЛАР хезмәтен кире кагып була

**Кредит бурычлары җыелганда банк коллекторларга кредит алган кешенең рөхсәте белән генә мөрәҗәгать итә ала.**

Россия Банкының 2020 елның 21 августында (№ ИН-015-59/123) дөнья күргән мәгълүмати хатында язылганча: кешенең куллану кредиты (займ) алганда төзелгән килешүдә, бурычлар җыелган очракта, банкка үз хокукларын (таләпләрен) өченче затларга тапшырырга рөхсәт итмәү мөмкинлеге бар. Аның бу теләге кредит килешүен төзегәндә каршылык тудырырга тиеш түгел.

2013 елның 21 декабрендә кабул ителгән «Куллану кредиты (займ) турында»гы 353нче федераль законның 5 маддәсе 9 өлеше 13 пункты нигезендә: куллану кредиты (займ) килешүе буенча хокукларны коллекторлар карамагына тапшырырга рөхсәт итмәү – индивидуаль шарт булып тора, шуңа күрә ул кредит бирүче белән кредит алучы тарафыннан шәхси тәртиптә килештерелә. Ягъни кредит алучыга сайлау хокукы бирелә. Мәсәлән, ул, бурыч җыелган очракта, кредиторга килешү буенча хокукны өченче затларга бирергә рөхсәт итә ала яки моны тыя. Әгәр тыя икән, бу – куллану кредиты (займ) алганда бернинди дә киртә тудырмаска тиеш.




**353нче федераль закон буенча, кредит алырга җыенган кеше банк белән килешүдәге шәхси шартларны, әлеге шартлар тәкъдим ителгән көннән башлап, биш эш көнендә (кредитор күбрәк срок билгеләмәгән булса) хәл итәргә бурычлы.**

Ул хәл иткән карар кредит (займ) килешүендәге шәхси шартлар язылган таблицаның 13нче графасында теркәлергә тиеш. Аның формасы Россия Банкының 2014 елның 23 апрелендәге «Куллану кредиты (займ) килешүенең шәхси шартлары таблица формасы турында»гы күрсәтмәсе (№ 3240-У) белән билгеләнгән.

# «Гадел БИЛГЕ»

2020 елның 1 ноябреннән Россиядә шин һәм автомобиль покрышкаларын мәҗбүри маркировкалау гамәлгә кертелде.

**2019 елның 31 декабрендә РФ Хөкүмәтенең 1958нче карары нигезендә Идентификация чаралары белән шиннарны маркировкалау кагыйдәләре расланды.**

Цифрлы икътисадта глобаль проектларны гамәлгә ашыру өчен «Гадел БИЛГЕ» («Честный ЗНАК») – Перспективалы технологияләрне үстерү үзәгенең цифрлы маркировка һәм товарларга күзәтчелек итү илкүләм системасы булдырылды. Махсус цифрлы код товарның чын булуын һәм сыйфатын гарантияли. «Честный ЗНАК» системасында товарларны әйләнешкә кертү, әйләнештә йөрүе һәм аннан чыгару турында мәгълүматлар урын алачак.

Смартфонында «Честный ЗНАК» мобиль кушымтасы урнаштырылган һәркем товарның легальлеген тикшерә ала. Моның өчен мобиль кушымта аша кодны сканер аша үткәрергә генә кирәк. Продукция турындагы бөтен мәгълүматны (җитештерүче, әзерләнгән датасы һәм урыны, яраклылык срогы һәм саклау шартлары, товарның тасвирламасы) белеп булачак.

**Россиядә продукцияне маркировкалау проекты этаплап гамәлгә ашырылачак:**

- ✔ 2020 елның 15 декабренә кадәр – Россия Федерациясенә 2020 елның 1 ноябреннән соң кертелгән, әмма 2020 елның 1 ноябренә кадәр сатып алынган шиннар маркировкалана. Маркировка турыдан-туры шинның үзенә төшерелә;
- ✔ 2020 елның 15 декабреннән – маркировкаланмаган шиннарны әйләнешкә кертү һәм әйләнештән чыгару тыела;
- ✔ 2021 елның 1 мартына кадәр – товар әйләнешендә катнашучыларның барысы да 2021 елның 15 декабренә кадәр сатылмаган товарларны маркировкаларга тиеш;
- ✔ 2021 елның 1 мартына кадәр – товар әйләнешендә катнашучыларның барысы да шиннарның әйләнештә йөрүе буенча барлык гамәлләргә кагылышлы мәгълүматларны «Честный ЗНАК» маркировкалау системасына тапшырырга бурычлы.



**МӨҺИМ!**

**Идентификация чаралары белән маркировкаланмаган продукцияне әйләнештә йөрткән һәм аны РФ территориясендә маркировкалау тәртибен бозган өчен РФ Административ хокук бозулар кодексының – 15.12 һәм РФ Җинаять кодексының 171.1 маддәләре буенча административ җаваплылык каралган.**